| | |
|---|---|
| ГЛАВА ЧУКМАРЛИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>САРМАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САРМАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЧУКМАРЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**02 ноябрь 2020 ел.** **№ 2**

2021 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Сарман муниципаль районы Чукмарлы авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Чукмарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2020 елның 13 ноябрендә 09.00 сәгатькә Татарстан Республикасы, Сарман муниципаль районы, Чукмарлы авылы, Совет урамы, 41 нче йорт адресы буенча урнашкан Чукмарлы авылы Мәдәният йорты бинасында 2021 елда Сарман муниципаль районының Чукмарлы авылы җирлегендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнарның 41 нче җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, ашыгыч хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортларының студентларыннан тыш, 200 сум күләмендә үзара салым кертүегез һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүегез белән килешәсезме:

1) Чукмарлы авылында авыл мәдәният йорты территориясен койма белән әйләндереп алу (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

2) Чукмарлы авылы зират коймасын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

3) кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

4) Чукмарлы авылы урамнарын яктырту объектларын карап тоту һәм хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);

5) Чукмарлы авылы спорт мәйданчыгы территориясен төзекләндерү (ком ташу);

« РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Чукмарлы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http://sarmanovo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сарман муниципаль районы
Чукмарлы авыл җирлеге башлыгы И.Х. Хадиуллин